РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 3-21-44

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Шэмэрдэн авылы, Лермонтов урамы, 2 йорт
тел. (84362) 3-21-44

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2018 № 31

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Шәмәрдән авыл җирлеге Советы тарафыннан
2014 нче елның 20 нче ноябрендә кабул ителгән
34 нче номерлы «Татарстан Республикасы
Саба районы Шәмәрдән авыл җирлегендә физик
затларның мөлкәт салымы турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым Кодексының 32 нче бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 64 нче маддәсенә туры китереп, Татарстан Республикасы Саба районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2014 нче елның 20 нче ноябрендә кабул ителгән 34 нче номерлы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы карары белән расланган “Шәмәрдән авыл җирлегендә физик затларның мөлкәт салымы турында” карарына (Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 2015 елның 5 нче августында кабул ителгән №33, 2015 елның 6 октябрендә кабул ителгән №9, 2018 елның 3 августында кабул ителгән №16 карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 2 нче пункты 2 нче пунктчасы 4 нче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“составына бер генә булса да торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплексларга”.

2. Әлеге карарның гамәлен 2019 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/kibiachi адресы буенча һәм авыл җирлегенең информацион стендларында бастырырга.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Гараев